

# Бакай авылы

## Борынгысы

## Уткәне

## Хәзергесе



***Авылымның ямен, суы тәмен беләм.***

***Шуңа күрә сөям, җаным, тәнем беләи.***

( Г.Тукай)

**Бакай.**

Кайда гына йөрсәм дә, кая гына барсам да, авылым күз алдыма килә һәм чиксез сагыну чолгап ала мине. “Хәр сандугач үз талын мактый”. Юк бу мактау гына түгел, бу – горурлану. Шулай булмыйча: зур- зур төзек йортлар, ике катлылары да күбәя бара, авыл уртасында урта мәктәп бинасы, классларда компьютерлар. Зур урамның нәкъ уртасында 1800 нче елларда салынган матур мәчет, дәвалану йорты, 6- 7 шәхси кибет, идарә йорты, клуб, китапханә...

Әтабигать?!
Авылыбызның буеннан- буена Акана елгасы ага. Ул авыл башындагы Сок елгасына коя,ә Сок Иделгә тоташа. Кечкенә таулар Урал тауларының итәгенә кадәр сузылган.

Урман бай. Урта зонада үсә торган бөтен төр агачлар да бар. Җәнлекләргә дә, җиләк- җимешенә дә, гөмбәсенә дә бай безнең урманнар. Киң болыннар, уңдырышлы кырлар, ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр. Билгеле, мондый бай табигатьле урынның, бай тарихы да булырга тиеш, әлбәттә.

... 13 гасыр башлары

Башкорт якларында туып үскән Бакый исемле асыл егет 25 елга патша армиясенә хезмәткә алына. Беркөнне патша чиновнигы үзенең якыннары белән ауга чыга. Хезмәтчеләре арасында яшь Бакый да була. Ау әйбәт кенә барган чагында, патша чиновнигы кинәт сазга бата башлый. Саз мәкерле, керергә куркыныч. Беркем дә якын барырга кыймый. Ә Бакый, ике дә уйлап тормыйча, чиновникка таба ыргыла һәм саздан тартып алып коткара. Икенче көнне чиновник аны үзе янына чакырып ала да әйтә: “Син мине үлемнән коткардың, нәрсә бирим: алтынмы, акчамы?”

“Миңа алтын да, байлык та кирәк түгел. Бир син миңа ирек һәм патша хезмәтеннән азат ит” – дип сорый Бакый. “Бүгеннән син һәм синең халкың ирекле, азат, - ди патша, - яшәгез, балалар үстерегез, бәхетле булыгыз”.

Риваять – менә шулай.

Чыннан да Бакый дигән егет үзенең дуслары белән атка атланып, бу якларга килеп чыга. Урманлы таулар, инеш- елга, киң болыннар – барысы да аның күңеленә хуш килгән.

Тиздән бу җиргә ул үзенең көтүләрен, хатынын хәм балаларын алып килгән, чатыр корып яши дә башлаган. Хатыны матур, уңган булган. Ул шушы чиста гына инештә керләр юган, савыт – саба чистарткан. Саф күңелле, чиста матур булганга, аны Ак ана дип йорткәннәр. Аның исеме белән инешне дә хәзер “Акана” дип йөртәләр. Ә авыл Бакый исеменнән – “Бакай” авылына әйләнгән. Бакыйның балалары үсеп, Сок елгасының үзәннәренә урнашып тора башлаганнар. Усман, Гали, Ярмәк – аның балаларының исемен йортәләр. Ә бер бай туганы, Байтуган дигән авылның үсеп китүенә сәбәпче булган. Хәзер болар шул исемдәге зур, бай татар авыллары.

1889 елны Бакай авылыбызда 280 йорт булган һәм 1728 кеше яшәгән (463 ир-ат һәм 1335 хатын-кыз). Аларның барысына бергә 5549 дисәтинә бүленгән җир тигән (5662 дисәтинә җайлы һәм 287 җайсыз). 1900 елны авылда 331 йорт һәм 1832 кеше булган (900 ир-ат һәм 926 хатын-кыз).

1910 елны авылыбызда 419 йорт исәпләнгән һәм 2343 кеше яшәгән (1149 ир-ат һәм 1194 хатын-кыз). Бакай Сок-Карамалы волостена кергән. Авылыбызда 2 сыйныфлы җайлаштырырылмаган мәктәп булган.

Бакай авылы зурайган, үскән. Әби – бабайларның сөйләве буенча, революция елларында авыл әле аклар, әле кызыллар кулында булган. “Тегеләр дә талады, болары да килеп таладылар”, - ди, бабайлар.

Минҗихан әби Шафигуллина сөйләгән бер кызыклы вакыйганы язып китәсем килә.

...1925 – 30 нчы елларда  авылда байлар да, ярлылар да яши. Кара Махирә атлы бик матур кыз булган авылда. Кара тут йөзле, зур кара күзле, озын кара чәчле булганга, Кара Махирә дип атаганнар аны. Чибәр һәм кыю булган кыз. Үзе тирәсенә батыр, кыю егетләрне туплап отряд төзегән кыз. Авылның төнягына урнашкан Ташкичү поселыгыннан өстә куе урманлы тауда землянкалар корып яши башлаганнар. Максатлары - байларны талап, ярлыларга өләшү. Отряд тулысынча кызга буйсынган.

Беркөнне Махирә Нури хаҗигә килгән. Берничә ат сораган. Хаҗи бирмәгән. Махирә, алай  булгач урлыйм, дигән. Урлый алсаң, урла, судлашып йормәм, дигән хәзрәт. Атлар яхшы, нык сарайда бик һәм сак астында торганнар. Беркөнне иртән хәзрәт чыкса, ни күрсен? Атлар юк! Бозау хәтле этләр исән, чабата хәтле йозак та ачылмаган.

- Урладың, ә? – дигән хәзрәт.

- Молодец, егет икәнсең. Атлар, синеке, - дигән.

Кара төндә атка атланган Махирәне бер генә күрмәгән авыл халкы. Яшен вакытында ап- ак атта, кап- кара чәчен туздырып авыл буйлап тезелгән таулар өстеннән чабып баруы бик хозур да, куркыныч та булган авыл халкына.

Соңыннан Кара Махирә Бөгелмә ягына китеп гомер иткән, диләр картлар. Менә бит, булган Бакайда да Галимҗан Ибраһимов геройлары!

Тоташ күмәкләшү елларында Akананы рәсми документларда Бакай дип йөртә башлаганнар.  Әби- бабайлар сүзләре буенча, авылда 1941- 1945 елгы сугышка кадәр дә, сугыштан соң да зур базар булган. Сатучы да, алучы да күп булган. Ябык лавкаларда кием- салым сатканнар. Тезелеп киткән рәтләрдә төрле размерда, төрле формада чабаталар, кувшин, чүлмәкләр дә,

май- каймак кебек әйберләр дә булган. Хәттә дөяләр белән казах якларыннан да килгәннәр. Кувшин чүлмәкләрнең төрле зурлыктагысын Памурзин чүлмәкче үзенең алачыгында эшләгән.



Авылыбыздан ерак түгел үзле балчык чокыры булган. Шул балчык белән чүлмәк ясаганнар. Һәрбер чүлмәкченең балчыкны яндырып чүлмәкләр ясар өчен үзенең махсус урыны булган.

Авыл әкрен генә күтәрелгән. Халык гади генә тормыш сөргән, иген иккән, мал асраган. Хатын-кызлар кул эше эшләгән: киндер тукыган, киез баскан. Авылның миччеләре, кое казучылары да булган. Чабата тукымаган бер генә йорт та булмаган диярлек.

Халык эш ысулларын җиңеләйтергә омтылган. Авылда биш ташлы тегермән эшләгән, анда он тарттырыр өчен күрше авыллардан да халык килгән. Авылда тимер алачык эшләгән, май чыгарту (көнбагыштан, җитеннән), итек бастыру урыннары, кулдан суккан әйберләрне буяуга ману урыны, тире, йон эшкәртү, киндер сугу өчен махсус урыннар да булган.

Авылның берничә кешесендә патефон булган. Флера Сөләйманова, Мәрьям Рахманкулова, Зифа Басыйрова, Усман Альмеев тавышлары ачык тәрәзәләрдән ишетелеп торган.

Репрессиягә эләгүчеләр дә булган. Шуларның берсен язып китәм. Бик эшлекле, халыкка тугрылыклы хезмәт итүче Шайхуллин исемле авыл советы рәисе булган. Совет йорты башындагы кызыл флаг бер- ике елдан аксылланган, уңган. Совет бинасы башына ак флаг элгәнсең, син халык дошманы, дип алып озатканнар.

Авылыбызның истәлекле урыннары турында язып китәм.

Бакай авылы зурайган. Аның тирәсенә кечкенә поселоклар аерылып чыгып үсә башлаганнар.

Ташкичү - Бакайның нәкъ төньягына урнашкан. Ул бер 20- 30 еллар гына яшәгән. 1970 нче елларда яңадан Бакайга кушылып беткән.

Зирекле – нәкъ Бакайның көньягында. Куе зирек агачлары арасыннан ага торган зур чишмә буена урнашкан. Кызганычка каршы бу авыл да елдан- ел кечерәя.

Ә менә көнчыгышта ике авыл урнашкан: Якты – күл хәм Тургай. Бакай белән Якты- күл арасында өч кечкенә күл булган. Сугыштан соңгы ыштансыз малайлар бу күлләрдән куллары белән балык чүпләгәннәр. Хәтта җәен балыгы да булган, дип сөйлиләр.

Әллә кайларга хәтле күренеп торган якты күлләр кипкән, ә авылга “Якты- күл” дип исем биргәннәр. Якты- күл нык, таза авыл, елдан- ел матурая, зурая. Аның башындагы ярты гектар чамасындагы әрәмәсе яз башында ап- ак чәчәккә күмелә.

Тургай поселогы. Бик күп булган тургайлар әрәмәдә, матур сайраганнар. Авыл хаман үсә. Авылдан 200- 300 м. читтәрәк  Мәскәү – Чиләбе – Себер автотрассасы үтә.

Тургайның төньягында Бакайның иң биек ноктасы – Очлы тау. Аның түбәсенә менеп, бөтен тирә – якны күреп була. Тауның  уртасында кыйблага таба чишмә агып тора.



Аның тирә- ягын укучылар карап, чистартып торалар. Эскәмиясенә утырып, кружкасыннан саф салкын суын эчеп җибәрсәң, бөтен тәнгә сихәт була. Бу чишмәдән су алырга килүчеләр өзелми. Чөнки суы күпме генә торса да бозылмый. Шуңа күрә авыл халкы аны “Изгеләр чишмәсе” дип атый. Чишмәгә олылар күп йөри.



Салкын суында тахәрәт алып, намаз укыйлар, теләкләр телиләр. Догалары кабул булсын өчен хәтта тиен акчалар да ташлыйлар суга. Беркем дә ул акчаларны алганы юк.

Тургайның төньягында зур матур болын. Ул Соковка ( урыс) авылының бакча башларына хәтле барып тоташа. Матур киенеп йөрергә яраткан көяз “землемер” бу болынны татар баена бер пар “кирзовый” итеккә саткан. Әй тырышканнар урыслар болыннарын кайтарып алырга! Әмма

патша пичәте язуга сугылган булган шул.


1962 нче елны Бакай авылы Куйбышев өлкәсеннән чыгып, Оренбург өлкәсенә кушылгач, эреләндерелгән зур колхозга – “Тукай” дип исем бирәләр.

“Торгынлык” дип аталган чорда авыл халкы – тукайлылар бертигез матур яшәгәннәр. Дүрт ферма, меңәрләгән гектар җир, техника, авыл халкын эшсез калдырмаган. Дөрестән дә, бакайлылар уңган халык. Бакчасын да чәчә, малын да асрый.

Авыл халкында матди яктан гына түгел, белемгә омтылыш та зур. Унберьеллык мәктәпне тәмамлап, яшьләр Казан, Самара, Оренбург югары уку йортларын бетереп, белгечләр булып чыгалар.


... 1960нчы еллар башында сигезеллык мәктәпкә татар теле хәм әдәбияты укытырга Илидә Бәширова дигән кыз килә. Ул Казан университетын бетерә. Балалар хәм авыл халкы аны бик тиз яратып өлгерә. “Татар теле нигә кирәк?”, дигән заманда, беренче мәртәбә ана- телебезгә мәхәббәтне ул тәрбияли. Хәзер Илидә Бәширова – тел белгече, профессор, Казанда яши. Авылыбыз татарлыгын югалтмыйча, миллилекне саклап кала белде. Хәзер хәр йорт диярлек татарча газета – журнал алдыра, Казанны карый.

Элекке вакытта безнең авылыбызда өч мәчет эшләгән.Һәм 1906 елны салынган мәчет бүгенге көндә дә халкыбызга иман нуры тарата, бүгенге көндә дә ул – авылыбызның горурлыгы, яме булып тора.



Авылыбызда олылар өчен генә түгел, балалар өчен дә мәчет рухи хәзинә булып тора. Мәчеттә биш вакыт намаз укыла, бик матур моңлы азан әйтелә. 20 елдан артык имам булып торган Хәлиулла Әбдулхәйров халыкны тәрбияләүдә, яшьләрне мәчеткә тарту өчен, күп көч куя. Ул манараны кистертмичә саклап калган.

Мәчет–ул татар авылының горурлыгы. Мәчет–ул сафлык, пакьлык урыны. Анда моңлы итеп биш вакыт азан әйтәләр, намаз укыйлар. Мәчетебездә азан әйткәндә, минем авыл халкымның күңелләре ямьләнеп, нурланып китә.



Мәчет каршында мәдрәсә төзелә хәм яшләрне укытырга югары органнардан рөхсәт алына.

Күп кенә яшьләр, апалар Коръән укырга өйрәнәләр, аның серләренә төшенергә тырышалар. Шуларның берсе – Сәлиха апа. Ул матур итеп Коръән уку гына түгел, бик күп бәетләрне дә аерым көйләргә салып укый белә.

Мактаулы хезмәте өчен исемен җырларга кушып җырларлык, романнарга, хикәяләргә герой итеп кертерлек кешеләр бар Бакай авылында. Мәсәлән, Мингазовлар династиясе (12 кеше – Мингазов Гали Фәтхи улының уллары, кызлары, оныклары, оныкчыклары Бакай мәктәбендә укытканнар һәм хәзерге вакытта да белем бирәләр; Тухватшин Мөҗаһит абый (колхозчыларның III-нче Бөтенсоюз съезды делегаты, колхозның баш агрономы) ; Хамидуллин Нурулла абый (колхоз председателе, Ленин ордены кавалеры); Шайхутдинов Әсхәт абый, данлыклы гармун ясаучы, тальян гармунда уйнаучы; бик күп тапкырлар сабантуй батыры Инсафутдинов Зәки абый; үзенең күз явын алырдай челтәр шәлләре белән дан тоткан Ахмадуллина Мәсхүдә апа һәм тагы бик күп уңган, батыр, сөйкемле һәм гади авыл эшчәннәре. Алар кунакчыл, эш сөючән, киң күңелле кешеләр. алар безгә, яшь буынга күңел җылысын өләшәләр, рухи дөньябызны баета, эстетик ләззәт бирә, хезмәткә мәхәббәт тәрбиялиләр.

Шундый кешеләре булган авылның табигате дә матур. Кайбер күркәм исемле матур урыннар турында язып китәсем килә.

Якты – күл белән Бакай арасында зур бер тал үсеп утыра. Ике кеше дә кара- каршы колачлый алмый аны.



Мортаза бабайның өе янында чишмә булган. Шуның кырыена тал утырткан бабай. Хәзер бабай үзе дә, өе хәм чишмәсе дә юк. Ә менә талы үскән дә үскән. Аны хәзер дә Мортаза талы дип йөртәләр.

Юл чатында ялгыз гына
Үсеп утыра карт кына тал.
Тирә ягы яшел чирәм
Ботаклары җиргә тигән.
Юл күрсәтә адашканга
Бу талыбыз бураннарда
Кавыштыра айлы кичтә
Яшерен утта янганнарны.
Юк инде ул Мортаза карт
Талы утыра истәлеккә,
Тырыш картны сагындырып,
Еллар буе искә төшерә.

Безнең яклар урманнарга да бик бай як. Иң якыны – "Бүләк" урманы. Июль аенда берәр аланына барып чыксаң, матурлыкка хәйран каласың. Нинди генә чәчәкләр юк анда. Авылыбызга бу чыннан да зур бүләк.

Чишмәләрне, хәтта урман эчендәгеләрне дә карап, чистартып тора авыл халкы. Су буе урамындагы "Кәшфелхак" чишмәсенә кемнәр генә килми. Һәрбер йортта насослы кое булса да, эчәргә дип, машиналар, атлар белән суга бу чишмәгә киләләр.





Авылыбызның Сок елгасы да бик чиста. Бер генә фермадан да Сок елгасына пычрак агып төшми. Шуңа күрә җәйге кызуларда бала- чага көне буе елга буенда.

Чиста хава, матур табигать төрле – төрле кошларны үзенә тартып тора: каргалар кычкырыша, чыпчыклар чыркылдый, тукран тукылдап ала. Әллә кайдан кәккүк тавышы яңгырый. Өздереп сандугач сайрый. Сандугач чиста, матур урында гына сайрый ул.

Менә минем авылым шундый!

